**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**КЛЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЛӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 56-0-39, факс 56-0-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31 .10. 2022** **№ 2**

**2023 елда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Келәш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Кляшево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Келәш авылы, Гагарин урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан Келәш авылы мәдәният йорты бинасында 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. 2022 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Келәш авылы, Ленин урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан «Арина» кибете бинасы янындагы урамда 15 сәгать 30 минутка билгеләргә.
3. 2022 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Келәш авылы, Гагарин урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан Келәш авылы мәдәният йорты бинасында 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегендә яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
1) " 2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, бары тик көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтәсезме:
- Келәш торак пунктында «ботка, ком» чишмәсенә керү юлын норматив халәткә китерү ( нигез салу, ташу, җәю, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне түләү) ;
- Келәш торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?».

"КАРШЫ" "РИЗА"

6. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.
7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан

Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/).
8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ф.Х. Галимов**